РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ КОРСАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422051, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Корсабаш, ул. Дорожная, 1
тел. (84362) 49-7-26

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУРСАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422051, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Курсабаш авылы, Юл урамы, 1 йорт
тел. (84362) 49-7-26

e-mail: korsab.sab@tatar.ru

24 сентябрь 2018 ел. — № 25

РЕШЕНИЕ — КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю һәм аны куллану буенча җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре турында” 12.06.2002 №67-ФЗ Федераль законның 15 нче статьясына, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында” 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законның 22.56 статьялары, Татарстан Республикасының “Җирле референдум турында” 24.03.2004 №23-ЗРТ 18 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясына туры китереп, Курсабаш авыл җирлеге Советының 15.09.2018 №24“Референдум уздыру инициативасы турында” карары, Курсабаш авыл җирлеге башкарма комитетының 15.09.2018 №26 “Референдум уздыру инициативасы турында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю соравын кертү буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга куеласы сорауларны түбәндәгечә расларга:

“Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Курсабаш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Курсабаш авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
- Сүлә авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
- Түбән Утар авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
- Югары Утар авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;

ӘЙЕ — ЮК”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка хәбәр ителгән) көннән соң үз көченә керә.

Курсабаш авыл җирлеге башлыгы — А.Р. Гимадиев